| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2017 Казан ш. № 5-71/тэ

Җылылык энергиясен тапшыру буенча җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләргә 2018 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылылык энергиясен тапшыру буенча җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләргә шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 08.12.2017
№ 5-71/тэ карарына кушымта

## Җылылык энергиясен тапшыру буенча җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләргә 2018 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | тариф төре | Ел | Җылысаклагыч төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Казан шәһәренең ЕТОЗ* эшләгән зонасында | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 272,56 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 278,65 | - |
| 2 | «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Казан шәһәренең ЕТОЗ* эшләгән зонасында | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 54,31 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 56,40 | - |

<*> - Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2015 елның 13 мартындагы 130 номерлы боерыгы белән расланган Казан ш. җылы белән тәэмин итү схемасына нигезләнеп билгеләнде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге